**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**№ 6/2** **2019 елның 2 апрелennән**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары һәм законнар үзгәреше мониторингын үткәрү турында Кагыйдәне раслау турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар һәм законнар үзгәреше мониторингын үткәрү буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбищеавыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль норматив хокукый актлары һәм законнар үзгәреше мониторингын үткәрү турында кушып бирелүче Кагыйдәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

-үзләренең нормалар булдыру эшчәнлекләрендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Кагыйдәгә нигезләнергә;

-күрсәтелгән Кагыйдәне үтәү өчен җаваплы затлар билгеләргә;

-җаваплы затлар итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләренә кирәкле үзгәрешләр кертергә.

3. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Җирлек башлыгы - Лаеш муниципаль районы**
**Столбище авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **В.В.Михеев**